СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон (8552) 70-00-33, факс 70-12-61, tukay.rt@tatar.ru

30.06.2026 № 11/6

На №_________ от_____________

# КАРАР

## Тукай муниципаль районында махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставына таянып,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районында махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне расларга (1 кушымта).
2. Махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләрен һәм аларның максатчан зурлыкларын, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольнең индикатив күрсәткечләрен расларга (2 кушымта).
3. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына үз норматив хокукый актларын әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе К.Р. Нәҗмиев

1 кушымта
Тукай муниципаль районы Советының 2026 елның 30 июнендәге 11/6 номерлы карары белән расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МАХСУС САКЛАНЫЛУЧЫ ТАБИГАТЬ ТЕРРИТОРИЯЛӘРЕН САКЛАУ ҺӘМ АЛАРДАН ФАЙДАЛАНУ ӨЛКӘСЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели (алга таба – муниципаль контроль).

1.2. Муниципаль контроль предметы булып тора:

1) җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрендә юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм гражданнарның (алга таба – контрольдәге затларның) «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында, махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында (алга таба – законнар) билгеләнгән, махсус сакланылучы табигать территориясе режимына; махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән, су объектларыннан, табигать ресурсларыннан һәм башка күчемсез мөлкәт объектларыннан файдалануның махсус хокукый режимына; махсус сакланылучы табигать территорияләренең саклау зоналары режимына кагылышлы мәҗбүри таләпләрне үтәү;

2) контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны үтәү.

1.3. Муниципаль контроль Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан аның төзекләндерү өлкәсендәге функциональ органы аша гамәлгә ашырыла (алга таба – контроль орган).

1.3.1. Контроль орган исеменнән муниципаль контрольне түбәндәге вазыйфаи затлар башкарырга хокуклы:

1) җитәкче (җитәкченең беренче урынбасары, җитәкче урынбасары);

2) әлеге Нигезләмә, вазыйфаи регламент яки вазыйфаи инструкция нигезендә вазыйфаи бурычларына муниципаль контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән профилактик чаралар һәм контроль чаралар уздыру керә торган контроль органның вазыйфаи заты (алга таба – инспектор).

1.3.2. Контроль чараны уздыру турында карар кабул итүгә контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затлары булып тора:

1) җитәкче;
2) җитәкченең беренче урынбасары;
3) җитәкче урынбасары.

1.4. Контроль орган тарафыннан муниципаль контроль гамәлгә ашырылганда, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) орган тарафыннан файдаланыла торган документларның типлаштырылган формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы нигезендә расланган типлаштырылган документ формалары кулланыла.

1.5. Контроль орган муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, үзе файдалана торган документларның Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) орган тарафыннан файдаланыла торган документларның типлаштырылган формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы нигезендә расланмаган формаларын расларга хокуклы.

1.6. Муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган мәсьәләләр «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 248-ФЗ номерлы Закон) белән җайга салына.

**2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычлары белән идарә итү**

2.1. Зарар (зыян) китерү куркынычын бәяләү максатында, планнан тыш контроль чара үткәрү һәм аның төрен сайлау турында карар кабул иткәндә, мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары кулланыла.

Куркыныч индикаторлары исемлеге Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының аерым карары белән раслана.

2.2. Планлы контроль чаралар уздырылмый.

2.3. Планнан тыш барлык контроль чаралар, прокуратура органнары белән килештерелгәннән соң гына, Россия Федерациясе Генераль прокуроры билгеләгән тәртиптә уздырылырга мөмкин.

2.4. Мәҗбүри профилактик визитлар үткәрелми.

**3. Муниципаль контроль кысаларында профилактика чаралары исемлеге**

3.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль орган түбәндәге профилактик чараларны үткәрә:
1) мәгълүмат бирү;
2) консультация үткәрү;
3) кисәтү белдерү;
4) профилактик визит.

3.2. Контроль орган контрольдәге затларга һәм башка кызыксынган затларга мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирә.

Мәгълүмат бирү 248-ФЗ номерлы законның 46 статьясы 3 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (https://tukay.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән,

дәүләт мәгълүмат системаларында контрольдәге затларның шәхси кабинетлары аша (алар булганда) гамәлгә ашырыла.
Контроль орган мәгълүматны башка формаларда: җыелышлар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, тематик очрашулар уздырганда һәм контрольдәге затларның бергә булуының башка формаларында бирергә; контрольдәге затларга мәҗбүри таләпләрне үтәү турында, шул исәптән контроль һәм профилактика чараларын уздыру барышында тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы.
3.3. Контроль органның вазыйфаи заты контрольдәге затларның һәм аларның вәкилләренең мөрәҗәгатьләре буенча консультацияләр үткәрә (муниципаль контрольне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә). Консультацияләр түләүсез үткәрелә.
3.3.1. Консультация бирү телефон аша, шәхсән кабул иткәндә яисә профилактик чара, контроль чара барышында башкарыла һәм 15 минуттан артмаска тиеш.
3.3.2. Контрольдәге затка контроль органның вазыйфаи заты тарафыннан телефон аша консультация бирү, телефон элемтәсенең техник чараларын кулланып, телдән башкарыла. Аны үткәрү вакыты, контакт телефоннары турында мәгълүмат контроль орган тарафыннан Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (https://tukay.tatarstan.ru ), контроль орган бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырыла.
3.3.3. Шәхси кабул итү җитәкче (җитәкченең беренче урынбасары, җитәкче урынбасары) тарафыннан үткәрелә.
Шәхсән кабул итүгә язылу урыны, вакыты һәм тәртибе турында мәгълүмат контроль орган тарафыннан Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (https://tukay.tatarstan.ru ), контроль орган бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырыла.
3.3.4. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан язма рәвештә консультация бирү, контрольдәге заттан консультация бирү мәсьәләләре буенча язма җавап бирү турында контроль органына язма запрос кергән очракта, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.
3.3.5. Календарь ел дәвамында бер типтагы биш һәм аннан күбрәк мөрәҗәгать кергән очракта, контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә консультация бирү Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (https://tukay.tatarstan.ru/ ) контроль орган җитәкчесе (җитәкченең беренче урынбасары, җитәкче урынбасары) имзалаган язма аңлатма урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.
3.3.6. Контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә консультация түбәндәге сораулар буенча башкарыла:
1) контроль чаралар үткәрү тәртибе;
2) контроль чараларны үткәрү ешлыгы;
3) контроль чаралар йомгаклары буенча карарлар кабул итү тәртибе;
4) контроль орган карарларына шикаять бирү тәртибе.

3.3.7. Консультация үткәргәндә, контроль органның вазыйфаи заты Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалануы чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга тиеш.
3.3.8. Консультация барышында конкрет контроль чарага, контроль органы вазыйфаи затларының, контроль чарада башка катнашучыларның карарларына һәм (яки) гамәлләренә бәяләмәне үз өченә алган, шулай ук контроль чара кысаларында уздырылган экспертиза, сынаулар нәтиҗәләре булган мәгълүмат бирелә алмый.
3.3.9. Консультация йомгаклары буенча контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә язма рәвештә мәгълүмат бирелми, әлеге Нигезләмәнең 3.3.4 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш.
3.3.10. Контроль орган консультацияләрне исәпкә алуны консультацияләр журналына тиешле язма кертү юлы белән гамәлгә ашыра, аның формасы контроль орган җитәкчесе тарафыннан раслана.
3.4. Контрольдәге затка мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә белдерелә һәм юнәлтелә һәм норматив хокукый актны күздә тоткан тиешле мәҗбүри таләпләргә күрсәтүне, контрольдәге затның конкрет нинди гамәлләре (гамәл кылмавы) мәҗбүри таләпләрне бозуга китерергә мөмкин булуы яки китерүе турында мәгълүматны, шулай ук әлеге таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрү турында тәкъдимне үз эченә алырга тиеш һәм контрольдәге затның белешмәләр һәм документлар тапшыру таләбен, контрольдәге затның мәҗбүри таләпләрне бозуга китерергә мөмкин булган яки китерә торган гамәлләре (гамәл кылмавы) нәтиҗәсендә барлыкка килгән зыяннарны бетерү срокларын үз эченә ала алмый.
3.4.1. Кисәтүне карау нәтиҗәләре буенча контрольдәге зат тарафыннан аны алганнан соң 20 эш көне эчендә кисәтү юллаган контроль органга каршылык тапшырылырга мөмкин. Каршылыкларда күрсәтелә:
а) контрольдәге затның исеме яки шәхси эшмәкәрнең яки физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);
б) салым түләүченең идентификация номеры;
в) котрольдәге зат адресына җибәрелгән кисәтү датасы һәм номеры;
г) контрольдәге затның кисәтүдә күрсәтелгән, мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга китерә торган яки китерергә мөмкин булган гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата позицияне нигезләү.
3.4.2. Кисәтүгә карата каршылыклар кәгазьдә почта аша яисә кисәтүдә күрсәтелгән контроль органның электрон почта адресына электрон документ рәвешендә, яисә кисәтүдә күрсәтелгән башка ысуллар белән җибәрелә.
Электрон документ рәвешендә җибәрелә торган каршылыклар электрон имза турында законнар нигезендә электрон имза белән имзалана, каршылыкларны электрон имза булганда да, электрон имза булмаса да җибәрә ала торган физик затлардан тыш.
3.4.3. Кисәтүгә карата каршылыклар контроль органның вазыйфаи затлары тарафыннан мондый каршылык алынган көннән башлап 20 эш көне эченедә карала. Контроль орган тарафыннан кисәтүгә карата каршылыкны карау нәтиҗәсендә түбәндәге карарларның берсе кабул ителә: кисәтүне үзгәртмичә калдыру; кисәтүне гамәлдән чыгару.

3.4.4. Каршылыклар булмаса, контрольдәге зат кисәтүдә күрсәтелгән срокта кисәтүнең үтәлеше турында контроль органга хәбәрнамә җибәрергә мөмкин.
3.4.5. Контроль орган мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамавы турында үзе белдергән кисәтүләрне исәпкә алуны гамәлгә ашыра һәм тиешле мәгълүматны башка профилактик чаралар һәм контроль чаралар үткәрү өчен файдалана.
3.5. Контрольдәге зат инициативасы буенча профилактик визит аның гаризасы буенча үткәрелергә мөмкин, әгәр ул кече эшмәкәрлек субъектларына караса, социаль юнәлешле коммерциясез оешма яисә муниципаль учреждение булып торса.
Профилактик визит контрольдәге затның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча профилактик әңгәмә формасында яисә видеоконференцэлемтә яки «Инспектор» мобиль кушымтасы ярдәмендә үткәрелә.
Профилактик визит барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр контрольдәгеы затларга бирелә алмый.
3.5.1. Контроль орган профилактик визитларны профилактик визитлар журналына тиешле язма кертү юлы белән исәпкә ала, аның формасы контроль орган җитәкчесе тарафыннан раслана.
3.6. Профилактик чаралар контроль органның вәкаләтле вазыйфаи заты карары белән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә раслана торган закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын профилактикалауның еллык программасы нигезендә контроль орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.
Расланган программа Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (https://tukay.tatarstan.ru) урнаштырыла.

**4. Контроль чараларның төрләре һәм һәр контроль чара составында мөмкин булган контроль гамәлләр исемлеге**

4.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль органның, аның вазыйфаи затларының контрольдәге затлар белән үзара хезмәттәшлеге булып инспектор белән контрольдәге зат яки аның вәкиле арасында очрашулар, телефон аша һәм башка сөйләшүләр (турыдан-туры хезмәттәшлек), документларны, башка материалларны соратып алу, инспекторның контрольдәге зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында булуы тора (инспекторның гомумән керергә мөмкин булган җитештерү объектларында булу очракларыннан тыш).
4.2. Контрольдәге зат белән үзара хезмәттәшлек түбәндәге контроль чараларны уздырганда гамәлгә ашырыла:
1) инспекция визиты;
2) рейд каравы;
3) документар тикшерү;
4) күчмә тикшерү.
4.2.1. Инспекция визиты, урынга барып тикшерү, рейд каравы үзара дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видеоконференцэлемтә аша, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.
4.3. Контрольдәге зат белән хезмәттәшлек итмичә түбәндәге контроль чаралар уздырыла:

1) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү;
2) күчмә карап тикшерү.
4.4. Инспекция визиты барышында түбәндәге контроль гамәлләр башкарылырга мөмкин:
1) карау;
2) сораштыру;
3) язма аңлатмалар алу;
4) инструменталь тикшерү;
5) контрольдәге зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яисә контроль объект урнашкан (эшчәнлек башкарган) урында мәҗбүри таләпләр нигезендә булырга тиешле документларны таләп итү.
4.4.1. Инспекция визиты контрольдәге затка алдан хәбәр итмичә үткәрелә.
4.4.2. Инспекция визитын эшчәнлекне гамәлгә ашыруның бер урынында яисә бер җитештерү объектында (территориядә) уздыру срогы бер эш көненнән артмаска тиеш.
4.5. Рейд тикшерүе производство объектын биләүче, файдаланучы яки аның белән идарә итүче теләсә нинди сандагы контрольдәге затларга карата үткәрелә.
4.5.1. Рейд тикшерүе барышында түбәндәге контроль гамәлләр башкарылырга мөмкин:
1) карау;
2) сораштыру;
3) язма аңлатмалар алу;
4) документларны таләп итү;
5) инструменталь тикшерү.
4.52. Рейд тикшерүен уздыру чорында контрольдәге бер зат белән хезмәттәшлек итү срогы бер эш көненнән артмаска тиеш.
4.6. Документар тикшерү контроль орган урнашкан урында үткәрелә.
4.6.1. Документар тикшерү барышында түбәндәге контроль гамәлләр башкарылырга мөмкин:
1) язма аңлатмалар алу;
2) документларны таләп итү.
4.6.2. Документар тикшерү уздыру срогы ун эш көненнән артмаска тиеш.
Документар тикшерү үткәрү срогын исәпләү туктатып торыла:
1) контроль орган тарафыннан контрольдәге затка документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны тапшыру таләпләре җибәрелгән вакыттан алып таләптә күрсәтелгән документларны контроль органга тапшырган чорга кадәр;
2) контрольдәге зат тарафыннан тапшырылган документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыклану яисә бу документлардагы белешмәләрнең контроль органдагы документлардагы һәм (яки) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында контроль органы мәгълүматын һәм күрсәтелгән язма аңлатмаларны контроль органга тапшырганчыга кадәр кирәкле язма аңлатмаларны тапшыру таләпләрен контрольдәге затка җибәргән вакыттан алып.
4.7. Күчмә тикшерү җитештерү объектларына ия булган һәм (яки) алардан файдаланучы конкрет контрольдәге зат белән хезмәттәшлектә, мондый затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләү, шулай ук контроль орган карарларының үтәлешен бәяләү максатында үткәрелә.

4.7.1. Күчмә тикшерү барышында түбәндәге контроль гамәлләр башкарылырга мөмкин:
1) карау;
2) сораштыру;
3) язма аңлатмалар алу;
4) документларны таләп итү;
5) инструменталь тикшерү.
6) пробалар (үрнәкләр) алу;
7) сынау;
8) экспертиза;
9) эксперимент.
4.7.2. Күчмә тикшерүне уздыру вакыты ун эш көненнән артмаска тиеш. Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата күчмә тикшерү үткәрү барышында үзара хезмәттәшлек итүнең гомуми срогы кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш. Үз эшчәнлеген Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә гамәлгә ашыручы оешмага карата күчмә тикшерү үткәрү срогы һәр филиал, вәкиллек, оешманың аерымланган структур бүлекчәсе яки җитештерү объекты буенча аерым билгеләнә.
4.8. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәткәндә (куркынычсызлык мониторингы) контрольдәге затларга мәҗбүри таләпләр белән билгеләнмәгән бурычлар йөкләнә алмый.
4.8.1. Әгәр мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы), барышында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яки зарар (зыян) китерү куркынычы барлыкка килү фактлары, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, әзерләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозулар яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр ачыкланса, контроль орган тарафыннан түбәндәге карарлар кабул ителергә мөмкин:
1) планнан тыш контроль чара үткәрү турында карар;
2) кисәтү белдерү турында карар;
3) 248-ФЗ номерлы законның 90 статьясы 2 өлеше 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар;
4) 248-ФЗ номерлы законның 90 статьясы 3 өлеше нигезендә, контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында беркетелгән карар, мондый мөмкинлек контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында күрсәтелгән очракта.
4.9. Күчмә тикшерү оешманың (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашкан (эшчәнлеген башкарган) урыны, граждан эшчәнлеген башкарган урыны, контроль объекты урнашкан урын буенча үткәрелә, шул ук вакытта контрольдәге зат белән үзара хезмәттәшлек рөхсәт ителми.
4.9.1. Гомумән кирәргә мөмкин булган җитештерү объектларына күчмә тикшерү барышында түбәндәге контроль гамәлләр башкарылырга мөмкин:
1) карау;
2) пробалар (үрнәкләр) алу;
3) инструменталь тикшерү (видеоязма кулланып);
4) сынау;

5) экспертиза.
4.9.2. Кучмә тикшерү контрольдәге затка хәбәр итмичә үткәрелә.
4.9.3. Кучмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча 248-ФЗ номерлы законның 90 статьясы 2 өлеше 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый, контроль төре турында Федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш.

**5. Контроль чаралар үткәрүне оештыру**

5.1. Контрольдәге зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан контроль чараны, шулай ук документар тикшерүне уздыру өчен, контроль орган тарафыннан контроль органның вәкаләтле вазыйфаи заты имзалаган карар кабул ителә, анда түбәндәге мәгълүмат күрсәтелә:
1) карар кабул итү датасы, вакыты һәм урыны;
2) кем тарафынна карар кабул ителгән;
3) контроль (күзәтчелек) чара уздыру нигезе;
4) контроль төре;
5) инспекторның (инспекторларның, шул исәптән инспекторлар төркеме җитәкчесенең) контроль чараны уздыруга вәкаләтле затның (затларның), шулай ук контроль чараны уздыруга җәлеп ителә торган белгечләрнең, экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), вазыйфасы яки мондый чараны уздыруга җәлеп ителә торган эксперт оешмасы исеме;
6) контроль чара уздырыла торган контроль объекты;
7) контрольдәге затның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны адресы яки контроль чара уздырыла торган башка контроль объектларының урнашу адресы рейд тикшерүенә карата күрсәтелмәскә мөмкин;
8) контроль чара уздырыла торган контроль объектының мәҗбүри таләпләргә туры килүе өчен җаваплы гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) яки оешманың исеме, оешманың (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) адресы рейд тикшерүенә карата күрсәтелмәскә мөмкин;
9) контроль чара төре;
10) контроль чара кысаларында башкарыла торган контроль гамәлләр исемлеге;
11) контроль чара предметы;
12) тикшерү кәгазьләре, әгәр аларны куллану мәҗбүри булса;
13) контроль чараны уздыру датасы, шул исәптән контрольдәге зат белән турыдан-туры хезмәттәшлек итү срогы (контрольдәге зат белән турыдан-туры хезмәттәшлек итү срогы өлешендә рейд тикшерүенә карата күрсәтелмәскә дә мөмкин);
14) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү өчен граждан, оешма тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге (контроль чара кысаларында контрольдәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатында документлар тапшыру каралган очракта).
5.2. Контроль чаралар контроль чараны уздыру турында контроль органы карарында күрсәтелгән инспекторлар тарафыннан уздырыла.
Кирәк булганда контроль орган контроль чараларны уздыруга билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән һәм экспертлар реестрына кертелгән экспертларны, эксперт

оешмаларын, контроль чаралар уздыруга җәлеп ителә торган эксперт оешмаларын җәлеп итә.

5.3. Контроль (күзәтчелек) чараларын үзара хезмәттәшлексез уздыруга карата әлеге контроль чараны уздыру турында карар кабул итү таләп ителми.

5.4. Контрольдәге зат булган шәхси эшмәкәр, граждан контроль чара үткәргәндә катнашу мөмкинлеге булмау турында мәгълүматны контроль органга тапшырырга хокуклы очраклар:

1) медицина учреждениесендә стационар дәвалануда булу;

2) Россия Федерациясеннән читтә булу;

3) контроль чара үткәргәндә катнашуга комачаулаучы җиңеп булмый торган хәлләр барлыкка килү (хәрби хәрәкәтләр, һәлакәт, табигый бәла-каза, эре авария, эпидемия һәм башка гадәттән тыш хәлләр).

5.5. Әлеге Нигезләмәнең 5.4 пунктында күрсәтелгән очраклар турында мәгълүмат үз эченә алырга тиеш:

1) хәлләрнең тасвирламасы һәм аларның дәвамлылыгы;

2) барлыкка килгән хәлләр һәм контроль чараны үткәргәндә катнашу мөмкинлеге булмау арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше турында белешмәләр;

3) контроль чараны үткәргәндә катнашуга комачаулый торган хәлләрне бетерү өчен кирәкле срокны күрсәтү.

5.6. Әлеге Нигезләмәнең 5.4 пунктында күрсәтелгән очраклар килеп чыкканда, контроль чараны үткәрү контроль орган тарафыннан шәхси эшмәкәрнең, гражданның контроль органга мөрәҗәгать итүенә сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерелә.

5.7. Инспектор һәм контроль гамәлләр кылуга җәлеп ителә торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләрен фиксацияләү өчен фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма, дәлилләрне теркәүнең башка ысуллары кулланылырга мөмкин, түбәндәгеләрне фиксацияләү очракларыннан тыш:

1) Россия Федерациясе законнары белән дәүләт серенә кертелгән белешмәләр;

2) Россия Федерациясе законнары нигезендә режимлы һәм аеруча мөһим объектларга кертелгән объектлар, территорияләр.

5.8. Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязманы гамәлгә ашыру тәртибе:

5.8.1. Контроль чараның барышын һәм нәтиҗәләрен фиксацияләү өчен әйләнә-тирәне, урынны, аерым өлешне һәм детальле фотога төшерү һәм (яки) видеоязма кулланыла.

5.8.2. Фотога төшерү, аудио- һәм видеофиксация видеорегистраторлар, пилотсыз очу аппаратлары, фотоаппаратлар, диктофоннар, видеокамералар, шулай ук мобиль җайланмалар (телефоннар, смартфоннар, планшетлар) ярдәмендә гамәлдәге законнарда билгеләнгән чикләүләрне исәпкә алып башкарылырга мөмкин.

5.8.3. Фото- һәм видеофиксация үткәрү өчен кулланыла торган җайланмада фотосурәтләрдә һәм видеоязмада агымдагы датаны һәм вакытны күрсәтү, шулай ук төшерү урыны (координаталар) турында мәгълүматны саклау техник мөмкинлеге булырга тиеш.

5.8.4. Аудиоязма контроль чараны үткәрү өчен җаваплы инспектор тарафыннан алып барыла.

5.8.5. Фото- һәм видеофиксация үткәргәндә түбәндәге таләпләр үтәлергә тиеш:

1) котроль объектының үзенчәлекләрен бозуны булдырмый торган фиксация алымнарын кулланырга кирәк;
2) алынган фотосурәтләр, видеоязмалар контроль объектларының үзенчәлекләрен мөмкин кадәр төгәл һәм тулы чагылдыра торган, мәҗбүри таләпләрне бозуны һәм объектны теркәү вакытын билгеләргә мөмкинлек бирә торган фиксация шартларын тәэмин итәргә кирәк.
5.8.6. Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма, геодезик һәм картометрик үлчәүләр үткәрү һәм бу максатлар өчен файдаланылган техник чаралар турында мәгълүмат контроль чарасы нәтиҗәләре буенча төзелә торган актта һәм, фиксация үткәрелгән җиһазның төрен һәм маркасын күрсәтеп, контроль чара кысаларында үткәрелә торган контроль гамәл нәтиҗәләре буенча төзелә торган беркетмәдә чагыла.
5.8.7. Фото-, аудио- һәм видеоматериаллар контроль чара актына кушымта булып тора.

**6. Контроль чара нәтиҗәләре**

6.1. Контрольдәге зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан контроль чара уздыру тәмамлангач, испектор контроль чара актын (алга таба – акт) төзи.
Үзара хезмәттәшлексез контроль чараны уздыру нәтиҗәләре буенча акт мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта төзелә.
6.1.1. Акт контроль чараны уздыру урынында мондый чараны уздыру тәмамланган көнне яисә, әгәр актны 248-ФЗ номерлы законда билгеләнгән сәбәпләр аркасында мондый чара уздырыла торган урында төзү мөмкин булмаса, әгәр актны рәсмиләштерүнең башка тәртибе 248-ФЗ номерлы законда яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәгән булса, мондый чараны уздыру тәмамланган көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча төзелә.
6.1.2. Контроль чара уздыру нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, актта нинди мәҗбүри таләпнең бозылуы, нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге белән билгеләнүе күрсәтелергә тиеш.
6.1.3. Ачыкланган хокук бозу контрольдәге зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан контроль чара уздыру тәмамланганчы бетерелгән очракта, актта аны бетерү факты күрсәтелә.
6.2. Контроль чараның дәүләт, коммерция, хезмәт сере, башка серне тәшкил итә торган мәгълүматны үз эченә алган нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.
6.3. Прокуратура органнары белән килештерелгән контроль чара акты бердәм контроль чаралар реестры ярдәмендә аны рәсмиләштергәннән соң ук прокуратура органнарына җибәрелә.
6.4. Контроль орган контроль чара үткәргәндә контрольдәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, вәкаләтле орган Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:
1) контроль чара актын рәсмиләштергәннән соң контрольдәге затка мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең нигезле срокларын, шулай ук контроль төре турында федераль законда каралган башка чараларны күрсәтеп, күрсәтмә бирергә;

2) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүне булдырмау яки аны китерүне туктату буенча (биналарны, корылмаларны, бүлмәләрне, җиһазларны, транспорт чараларын һәм башка шундый объектларны эксплуатацияләүне (файдалануны) тыю турында таләп белән судка мөрәҗәгать итүгә кадәр) Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кичекмәстән күрергә, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычы булу һәм аны булдырмый калу ысуллары турында мәгълүматны гражданнарга, оешмаларга теләсә нинди мөмкин булган ысул белән җиткерерү турында, әгәр контроль чара үткәргәндә контроль объектына ия булучы һәм (яки) файдаланучы гражданның, оешманың эшчәнлеге, алар тарафынна биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, бүлмәләрне, җиһазларны, транспорт чараларын һәм башка шундый объектларны эксплуатацияләү (файдалану), башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычы тудыра яки мондый зарар (зыян) китерү очрагы булса;

3) контроль чара барышында җинаять яисә административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, тиешле мәгълүматны үз компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрергә яки, тиешле вәкаләтләр булганда, гаепле затларны законда билгеләнгән җаваплылыкка тарту чараларын күрергә;

4) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне контрольдә тоту, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү ихтималын булдырмау буенча чаралар күрергә, билгеләнгән срокларда күрсәтмә үтәлмәгәндә, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турында таләп белән, судка мөрәҗәгать итүгә кадәр, аны үтәүне тәэмин итү чараларын күрергә, әгәр мондый чара законнарда каралган булса;

5) мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча рекомендацияләр бирү, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын профилактикалауга юнәлтелгән башка чаралар үткәрү турында мәсьәләне карарга.

6.5. Документар тикшерү уздырганда күрсәтмә контрольдәге затка документар тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

6.6. Әлеге Нигезләмәнең 6.4 пункты 1 пунктчасы нигезендә кабул ителгән карарны контрольдәге зат трафыннан үтәү срогы тәмамлангач, яисә контрольдәге зат әлеге карар белән тапшырылуы билгеләнгән документларны һәм белешмәләрне күрсәтелгән срок тәмамланганчы тапшырганда, яисә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) кысаларында мәгълүмат алынган очракта, контроль орган карарның үтәлешен тапшырылган документлар һәм белешмәләр, алынган мәгълүмат нигезендә бәяли.

6.7. Әгәр күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр контрольдәге зат тарафыннан тапшырылмаган булса яки алар нигезендә яисә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) кысаларында алынган мәгълүмат нигезендә карарның үтәлеше турында нәтиҗә ясау мөмкин булмаса, контроль орган әлеге карарның үтәлешен инспекция визиты, рейд тикшерүе яки документар тикшерү уздыру юлы белән бәяли. Әгәр күчмә тикшерү йомгаклары буенча кабул ителгән карарның үтәлешен бәяләү үткәрелсә, күчмә тикшерү уздыру рөхсәт ителә.

6.8. Контрольдәге зат күрсәтмәне үтәгән очракта, контроль орган контрольдәге затка күрсәтмәнең үтәлеше турында хәбәрнамә җибәрә.
6.9. Әлеге Нигезләмәнең 6.7 пунктында каралган контроль чараны үткәрү йомгаклары буенча карарның үтәлмәве яисә тиешенчә үтәлмәве контроль орган тарафыннан ачыкланган очракта, ул яңадан контрольдәге затка әлеге Нигезләмәнең 6.4 пункты 1 пунктчасында каралган карарны, аны үтәүнең яңа срокларын күрсәтеп, кабат бирәчәк. Күрсәтелгән срокларда күрсәтмә үтәлмәгәндә, контроль орган аны үтәүне тәэмин итү чараларын күрә, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турында таләп белән судка мөрәҗәгать итүгә кадәр, әгәр мондый чара законнарда каралган булса.
6.10. Акт һәм аңа теркәп бирелә торган материаллар контроль чара тәмамланганнан соң өч ел дәвамында контроль орган тарафыннан сакланырга тиеш.
6.11. Мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган контрольдәге зат ачыкланган мәҗбүри таләпләрне тиешенчә бетерү турында контроль орган белән килешү төзү турында үтенечнамә бирергә хокуклы (алга таба – килешү).
Килешүне төзү, үзгәртү, озайту, өзү тәртибе, килешү шартлары, килешү төзү хокукына ия затлар даирәсе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

**7. Контроль орган, аның вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмаувына) шикаять бирү**

7.1. Алар фикеренчә, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган контрольдәге затлар судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:
1) контроль чаралар уздыру турында карарларга;
2) контроль чаралар актларына, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәләргә;
3) контроль чаралар кысаларында контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына).
7.2. Вәкаләтле орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять контрольдәге зат үз хокукларының бозылуы турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.
Шикаять бирү срогы нигезле сәбәпләр аркасында үткәрелгән очракта, шикаять бирүче затның үтенече буенча бу срок контроль орган тарафыннан кире торгызылырга мөмкин.
7.3. Контроль органның күрсәтмәсенә шикаять контрольдәге зат күрсәтмә алган мизгелдән ун эш көне эчендә бирелергә мөмкин.
Шикаять бирү срогы нигезле сәбәпләр аркасында үткәрелгән очракта, шикаять бирүче затның үтенече буенча бу срок контроль орган тарафыннан кире торгызылырга мөмкин.
7.4. Шикаять «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан һәм (яисә) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» региональ мәгълүмат системасыннан файдаланып, контроль органга электрон рәвештә тапшырыла, әлеге Нигезләмәнең 7.5 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш.
Шикаять көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән, тикшерү ачкычы сертификаты электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара

хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада төзелгән һәм кулланыла торган көчәйтелгән квалификациясез электрон имза белән, яисә физик затның, шул исәптән юридик зат исеменнән (җитәкче яки тиешле вәкаләтләр бирелгән зат, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып) яки шәхси эшмәкәр булган затның гади электрон имзасы белән имзалана.
7.5. Дәүләт серен яисә закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне һәм документларны үз эченә алган шикаять, дәүләт сере һәм закон белән саклана торган бүтән сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, контроль органга кәгазьдә яисә почта аша җибәрелә.
7.6. Шикаять судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасында теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә контроль орган тарафыннан каралырга тиеш.
7.7. Контроль орган шикаятьне караганда контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенең судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасыннан файдалана, шикаятьне карау дәүләт серен яки закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклардан тыш, һәм шикаятьне карау барышы турында белешмәләрне контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенең судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасына тапшыруны тәэмин итә.
7.8. Кабул ителгән карарны нигезләүне, аны үтәү срогын һәм тәртибен үз эченә алган контроль орган карары Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында һәм (яки) Региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында контрольдәге затның шәхси кабинетында ул кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.
7.9. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка шикаять бирү судка кадәр шикаять белдерелгәннән соң гына бирелергә мөмкин, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмаган гражданнар карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка шикаять биргән очраклардан тыш.
7.10. Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр шикаять бирү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.
**8. Контроль объектларын исәпкә алу**
8.1. Контроль орган 248-ФЗ номерлы закон, әлеге Нигезләмә нигезендә контроль объектларын исәпкә алуны тәэмин итә.
8.2. Контроль объектларын исәпкә алу контроль орган тарафыннан контроль орган җитәкчесе раслый торган типлаштырылган форма нигезендә рәсмиләштерелә торган контроль объектларын исәпкә алу журналын алып бару юлы белән гамәлгә ашырыла.
8.3. Контроль орган контроль объектлары турында белешмәләрне җыйганда, эшкәрткәндә, анализлаганда һәм исәпкә алганда, аларны исәпкә алу максатында, аңа норматив хокукый актлар нигезендә бирелә торган мәгълүматтан, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган мәгълүматтан, шулай ук һәркемгә ачык мәгълүматтан файдалана.
8.4. Контроль объектларын исәпкә алганда, контрольдәге затларга белешмәләр, документлар тапшыру бурычы йөкләнә алмый, федераль законнарда башкасы

каралмаган очракта, шулай ук тиешле белешмәләр, документлар дәүләт яисә муниципаль мәгълүмат ресурсларында булса.
8.5. Контроль объектларын һәм аларга бәйле контрольдәге затларны исәпкә алу мәгълүмат системалары булдыру юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

**9. Контроль орган эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләү**
9.1. Контроль орган эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын бәяләү муниципаль контрольнең нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләре системасы нигезендә гамәлгә ашырыла.
9.2. Контроль орган эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләре системасына түбәндәгеләр керә:
1) махсус саклапылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольнең закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарарны (зыянны) минимальләштерү дәрәҗәсен, максатчан (планлы) күрсәткечләр билгеләнә торган һәм аларга ирешүне контроль орган тәэмин итәргә тиешле эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә зарар (зыян) китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсен чагылдыра торган төп күрсәткечләре;
2) махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольнең контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген мониторинглау, аны анализлау, аны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган проблемаларны ачыклау һәм аларның зарар (зыян) китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсе белән хезмәт, матди һәм финанс ресурслары күләме арасындагы нисбәтне характерлаучы килеп чыгу сәбәпләрен ачыклау өчен кулланыла торган индикатив күрсәткечләре, шулай ук контрольдәге затларның эшчәнлегенә катышу дәрәҗәсе.
9.3. Контроль орган ел саен, җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төп күрсәткечләргә ирешү турында белешмәләрне һәм муниципаль контрольнең индикатив күрсәткечләре турында белешмәләрне күрсәтеп, контроль төре турында, шул исәптән профилактик чараларның һәм контроль чараларның төп күрсәткечләргә ирешүгә йогынтысы турында доклад әзерләүне, шулай ук хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча тәкъдимнәр әзерләүне гамәлгә ашыра.

2 кушымта
Тукай муниципаль районы Советының 2026 елның 30 июнендәге 11/6 номерлы карары белән расланган

Махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан зурлыклары, махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольнең индикатив күрсәткечләре

| 1 | Төп күрсәткечләр | Максатчан зурлыклары |
|---|---|---|
| 1.1 | Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозулар арасында бетерелгәннәре өлеше | 75 |
| 1.2 | Контроль чараларның суд тәртибендә юкка чыгарылган нәтиҗәләре өлеше | 5 |
| 1.3 | Контроль чаралар уздырганда контроль органның һәм (яки) аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезләнгән шикаятьләр өлеше | |
| 2 | Индикатив күрсәткечләр | Берәмлек |
| 2.1 | Профилактик чаралар үткәрелде | Саны |
| 2.2 | Контроль чаралар үткәрелде | Саны |
| 2.3 | Мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирелде | Саны |
| 2.4 | Мәҗбүри таләпләрне бозулар бетерелде | Саны |
| 2.5 | Контроль чаралар актларына карата каршылыклар килде | Саны |